ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

16.12.2021 Казан ш. № 634-26/э-2021

«Казан энергетика компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 №3-12/э карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларының кирәкле тулай табышына 2022 ел өчен үзгәреш кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2024 елларга «Казан энергетика компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә индивидуаль тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019 № 3-12/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2020 № 395-11/э-2020 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);
3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы С.В.Павлов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-12/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 № 634-26/э-2021 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Татарстан Республикасы территориясендә «Казан энергетика компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| Т/с | Челтәр оешмасының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Казан энергетика компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2020 | 265 191,40 | 45,35 | 0,68591 | 265 191,40 | 45,35 | 0,68591 |
| | | 2021 | 314 140,38 | 61,37 | 0,79854 | 314 140,38 | 61,37 | 0,79854 |
| | | 2022 | 360 095,75 | 65,07 | 0,90988 | 360 095,75 | 65,07 | 0,90988 |
| | | 2023 | 275 643,31 | 48,11 | 0,69696 | 275 643,31 | 49,55 | 0,69768 |
| | | 2024 | 279 572,87 | 49,55 | 0,70243 | 279 572,87 | 51,04 | 0,70317 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-12/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2021 № 634-26/э-2021 карары редакциясендә) 3 нче кушымта

## «Казан энергетика компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2020-2024 елларга кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| Т/с | Татарстан Республикасындагы челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | «Казан энергетика компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2020 | 56 934,47 |
| | | 2021 | 78 247,34 |
| | | 2022 | 89 695,39 |
| | | 2023 | 72 392,35 |
| | | 2024 | 74 564,12 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге